# Авыл шулай тазара

**Безнең Апас районындагы Түбән Барыш авылы олы тау астына урнашкан. Бирегә беренче булып 1512 елны Мирза Барышников һәм Хабул исемле чуашлар килеп урнашкан дип сөйлиләр.**

Имеш, авылның исеме шуннан Барыш булып киткән. Аннан соң бу якларга татарлар күченеп утыра башлаган. Алар атлар белән йөрер өчен тауларга юл салырга тотынган. Һәрбер тауга аерым исем бирелгән: Морзалаш тау, Хабулла тау, Шәйхетдин тау, Акчалы тау, Кала тавы һәм башкалар. Һәрбер тауның итәгеннән чишмә агып чыга. Аларның саны сигезгә тула. Бабаларыбыз суга бик сак мөнәсәбәттә булган. Кизләүләрнең тамагын ачып, аны киңәйткәннәр, шуннан соң агач бура батырганнар, улаклар ясаганнар. Һәрбер чишмәгә исем кушылган: Изгеләр чишмәсе, Шәйхетдин бабай чишмәсе, Хафиз бабай чишмәсе, Идрис бабай чишмәсе.

Авыл кырыеннан Үләмә елгасы ага. Элек авыл уртасында кечкенә генә күл булган. Тау итәгендәге чишмәләр шунда агып төшкән. Ә күл Үләмәгә тоташкан. Идрис бабай чишмәсе белән Акчалы тау чишмәсен бергә кушып, күл буенча су тегермәне утыртканнар. Суы җитмәгәнгә күрә, 1912 елны аны казып, зурайтканнар. Туфрагын атларга төяп, кырга түккәннәр. Хәзерге вакытта әлеге күл җиде гектар җирне били. Аның тирәягына агачлар утыртылган. Безнең бабаларыбыз менә шулай бердәмләшеп эшләгәннәр, үз тормышларын үзләре ямьләгәннәр, читтән ярдәм көтеп, кул кушырып утырмаганнар.

Ә хәзер заманалар үзгәрде. Чишмәләрдән килә торган су торбаларга куып кертелде. Ферма терлекләре дә шуннан эчә, халыкның өенә дә су кергән. Чишмәләргә бабайлар утырткан буралар череде инде. Тауларда көтү йөри, сулар пычрана башлады. Район башлыгы итеп Рәшит Зәһидуллин билгеләнгәннән соң менә шул ташландыкка әйләнеп бара торган кизләүләргә кабат игътибар артты. Безнең авыл җирлегенә быел Рузия Низамованы рәис итеп сайлап куйдык. Ул да эшне чишмәләрдән башлады. Иң әүвәл авыл урамнары тазартылды. Аннан соң: "Кәфил абый, чишмәләрне яңартып булмасмы икән?" – дип миңа мөрәҗәгать итте. Без пенсионер картлар белән җыелышып сөйләштек тә, урманга барып баганалар, киртәләр әзерләдек. Һәрбер кирткә баганалар утыртып рәшәткә белән әйләндердек, аннары буяп та куйдык. Кичен эштән кайткач, авыл яшьләре дә булышырга килде.

Бу эшне бердәм башкарып чыкканнан соң Рузия, авыл халкы белән сөйләшеп, күлне чистарттырды. Терлекчеләр белән киңәшләшеп, мәчетне юып чыгардылар. Зиратны чистарттык. Рәисебез кабат яныма килде: "Кәфил абый, үсентеләр алып кайтып булмасмы?" – дип сүз катты ул. Мин, урманга барып, 38 төп агач үсентесе алып кайттым. Шомырт, миләш, каен үсентеләрен мәчет, кибет, ишегалларына утыртып чыктык. Хәзер чишмәләребезне көтүләр таптамый. Аккан суларыбыз чиста. Әйтәсе килгән сүзем шул: авыл җитәкчеләре халык белән уртак тел табып эшне оештыра белсәләр, моңа беркем дә каршы килми. Табигать биргән байлыкларның кадерен белик, авылыбызның рухын изге саклыйк, дип яшибез.

**Кәфил МОСТАФИН**





# Апастагы могҗиза

Апас районы Җиде Кизләү авылында гаҗәеп матур бер чишмәгә юлыктык. Ургылып агучы бу чишмә яныннан тыныч кына үтү мөмкин түгел иде. Машинабызны туктатып, чишмә җырын тыңлап, фонтан арасында йөзеп йөргән каз-үрдәкләргә хозурланып, әкиятләрдә генә була дип уйлый торган татлы суын эчеп кайттык без.

Соңгы елларда республикада чишмәләрне төзекләндерүгә шактый игътибар бирелә. Бу яктан башкаларга үрнәк итеп нефтьчеләрне күрсәтергә була. Ләкин Апас – чиста авыл хуҗалыгы районы, биредә нефтьчеләр дә юк. Мондый матурлыкны кем тудырган икән дигән сорау күңелне кытыклап куйды.


Җиде Кизләү авылы Сатламыш җирле үзидарәсенә керә. Әлеге җирлек җитәкчесе Заһид Шәрәфиев белдергәнчә, бу авылда борын-борыннан чишмәләр күп булган. Салага исем сайлаганда, су чыганакларының күп булганлыгын исәпкә алып, шулай атаганнар икән.

– Әлеге чишмә юл буенда урнашкан. Шуңа күрә дә үткән кешеләр аңа сокланып китә. Авылдагы башка чишмәләр дә төзек хәлдә. Җиде Кизләүнең горурлыгы булган бу табигать нигъмәтләрен халык бик кадерләп, саклап, чистартып тора. Сез күргән чишмәне исә инде күптәннән район хакимияте эшләткән иде, – ди Заһид Зәйнетдин улы.

Чишмә безнең кебек юлаучыларның яраткан урынына әйләнгән. Җир-анадан ургылып чыккан саф суны эчеп бик күпләр үзләренә сихәт, чишмәгә карап утыручылар күңелләренә тынычлык алып китә икән. Энергия алу өчен фонтан янында утырган пар аккошлар янәшәсендә йөзеп йөргән үрдәкләрне, баскычлардан дулкын кебек агучы суның матурлыгын тоемлау өчен үзең күрү кирәк шул.

Без, гадәттә, чишмәләрне талгын гына улактан ага дип уйлыйбыз. Җиде Кизләү чишмәләре башка авылдагыларыннан бик нык аерыла. Ул җиде таш баскыч аша төшә. Саланың төп горурлыгы булган мондый чыганакларны киләчәк буын да сакласа иде.

**Лилия НУРМӨХӘММӘТОВА**



# Күз буяу түгел бу



**Район үзәкләре арасында Алексеевск үзенең җыйнаклыгы һәм матурлыгы белән аерылып тора. Әлеге фикер Татарстанның экологик иминлек, табигатьтән файдалану һәм санитар эпидемиологик куркынычсызлык буенча ведомствоара комиссия утырышында кат-кат яңгырады.**

Комиссия әгъзалары бирегә 2008 елның 24 апрелендә килеп, төбәкнең экологиясен яхшырту буенча махсус карар кабул иткәннәр иде. Бу юлы шуның үтәлеше белән танышу өчен җыелдылар. Аксубай, Алексеевск, Әлки, Спас, Чистай һәм Яңа Чишмә муниципаль районнарында экологияне яхшырту өчен әлеге документта билгеләнгән чаралар үтәлгәнме? Менә шуны ачыклау иде максатлары.

Кунаклар иң башта Алексеевск бистәсенең киң, чиста урамнарын карап үттеләр. Аннан соң каты көнкүреш калдыклары (ККК) полигоны, калдык суларны чистарту корылмалары һәм асфальт-бетон заводы белән таныштылар. Экология һәм табигый байлыклар министры Әгъләм Садретдинов комиссия әгъзаларының игътибарын элеккеге чүп-чар урыннарында хәзер бәреп торган фонтаннарга юнәлтте. Бер ел эчендә бистәне нәҗесләп торучы урыннарның эзе дә калмаган. Балык чирттереп ял итәрлек матур күлләр, яшь наратлар үсеп утырган парклар барлыкка килгән.

Алексеевскиның ККК полигоны эшчәнлеге дә аерым игътибарга лаек. Биредә көнкүреш калдыкларын аралап, гамәлгә яраксызларын пресслыйлар һәм чүплеккә озаталар. Ә икенчел чимал булырдайларын җыеп, акча эшлиләр. Күп кенә операцияләр механизацияләнгән һәм автоматлаштырылган булу сәбәпле, монда хезмәт куючыларның саны да зур түгел. Элек чүп-чар белән тулган алагаем зур чокыр күмдерелгән һәм аның өстендә хәзер парк хасил булган. Башка чүп базларын да шундый киләчәк көтә икән.

Калдык суларны чистарту корылмасы эшчәнлегенә шулай ук кыек сүз әйтерлек түгел. Аннан агып чыккан су төшүче камышлы күлдә йөзеп йөргән кыр үрдәкләрен һәм аккошларны күргәч, кунаклар телсез калды дияргә була. Без – күз буярга маһир халык булсак та, мондый төр киекләрне кунакларга күрсәтер өчен генә суга төшереп булмый торгандыр. Алар бу күлне үз иткәнгә күрә һәр язын килеп оялыйлар, бала чыгаралар. Димәк, корылма ташландык суларны әйбәт чистарта. Һәм аннан чыккан агым Алексеевск бистәсе утырган ярларны юучы Чулманга зыян салмый.

Алексеевск юллар төзү компаниясенең Бутлеровка авылы янындагы асфальт заводы территориясендәге чисталык һәм тәртипне күреп тә комиссия утырышына килгән кунаклар соклanulы хисләр кичерде. Аларның күбесе мондый төр предприятиеләрдә күзәтелә торган тәртипсезлек һәм шыксызлыкка иялəшкәндер, мөгаен. Биредә исә хезмәт куючылар өчен һәр төрле уңайлыклар булдырылган. Мондый пөхтәлекне, матурлыкны шулай ук бер атна эчендә генә кунакларга күрсәтү өчен көйләп өлгереп булмый.

Районда тирә-юнь мохитне савыктыру буенча кылынган гамәлләр белән танышканнан соң, ведомствоара комиссия әгъзалары Кама аръягы зонасына кергән башка районнарның бу юнәлештәге эшчәнлеге турында сөйләшеп алырга булдылар. Ул әнә шул былтыргы карар үтәлешен чагылдырган фильм караудан башланды. Аянычка, фильм барышында күп кенә районнарның вәкилләренә кызарынып утырырга туры килде. Ә аннан соң Аксубай, Әлки, Яңа Чишмә кебек районнарның җаваплы хезмәткәрләренә, сүз алып, аклану мөмкинлеге бирелде. Карарда күрсәтелгән чараларны үтәүгә битараф калган Әлки муниципаль районына 2010 елның апрелендә, Аксубайга майда барып, аларның әйләнә-тирә мохитне тазартудагы эшчәнлеген урында тикшерергә булдылар.

Чынлап та, Татарстан экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары А.Щеповских һәм табигатьтән файдалану өлкәсенә федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Л.Гайнетдинованың чыгышларында китерелгән саннар һәркемне дә уйландырырлык. Республика шәһәр һәм авылларыннан чүплекләргә озатылган сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары арасында ел саен 850 миллион сумлык икенчел чимал күмелеп кала икән. Бу – кыйммәт йөргән төсле һәм кара металл, кәгазь, чүпрәк-чапрак, пыяла ватыклары, чытыр элпәләр араланып, икенчел эшкәртүгә җибәрелми дигән сүз.

Министр Әгъләм Садретдинов утырышта катнашучыларның игътибарын тагын бер мәсьәләгә юнәлтте: һәр чүп полигонының хуҗасы булырга тиеш.

– Безнең алда беренчел бурыч, көнкүреш калдыкларының, аралап, пресслап түгелә торганының күләмен киметү булса, икенчесе – терлекчелек тармагыннан чыга торган калдыкларны утильләштереп табыш алу, – диде ул. – Тирестән биоягулык һәм яхшы сыйфатлы органик ашлама эшләп чыгаруга керешер вакыты җитте.

Минемчә, ведомствоара комиссиянең утырышларны менә шулай районнарга чыгып үткәрүе бик үтемле. Ул видеоконференция режимында уздырылганлыктан, анда комиссия әгъзаларыннан тыш, районнарның башкарма комитет җитәкчеләре, прокуратура вәкилләре, экология һәм табигый ресурслар өчен җаваплы башка белгечләр дә катнаша.

**Шәһит ГАТАУЛЛИН**

# Рәнҗештән куркыгыз

ЯХШЫЛЫККА КАРШЫ – НАЧАРЛЫК

**Быелгы түзеп булмаслык кызу чилләдә, корылыктан туфрак тәмам кибеп, басулар коргаксып ятты. Олыкарының яңгыр теләп ялварган күзе көйдергеч кояш нурлары астында төсе уңа башлагандай тоелган зәңгәр күк йөзеннән китмәде. Менә шундый эссе җәй җылы көзгә тоташкан коп-коры көннәрдә Салдакай авылында көмеш сулы чишмәнең тирәннән бәреп чыгуы көтелмәгән могҗизага тиң булды. Күктән иңмәсә, җирдән биргән Аллаһы Тәгалә кодрәте бу.**

Ә бит ямьле Чирмешән буенда утырган бу авылда челтер тавышлы андый чыганакның эзе дә күренмәгән элек. Борылып-сарылып ага торган ошбу елганың Кызылъяр дигән аулак җирендә пәйда булуын гына күр син гөрләвек кизләүнең. Авыл кешеләре яр читендә су саркып ятканын күргәч, ул урынны казып, чистартып, чишмәнең тамагын киңәйттеләр. Чишмә күзенә агач бура төшерделәр, өстенә чиләкле чыгыр астылар. Тирәягын тигезләп, ян-якларга агач утырткач, оҗмах төсен алды Кызылъяр.

Бу гамәл соңгы елларда ярлары ишелеп, ләмгә күмелеп, сулары кимеп барган Чирмешәннең агым юлын ныгыту өчен дә бик вакытлы булды. Авыл җирлеге җитәкчеләре оештырган әлеге экология чарасын халык хуплап каршылады. Төбәктәге җирләрне, басу юлларын аждаһа сыман куәтле, авырдан-авыр техникасы белән изеп-сытып йөрүче нефтьчеләрнең дә аны төзекләндерү өчен матди булышлыгы кирәк булып чыкты. Боларның кулы тигәч, чишмә һәм аның янягы тулысынча төзекләнделмичә калмас дип өметләнә халык. Мәчет картлары, намаз карчыклары бу изге урында гыйбадәт кылып, хәер-фатихасын биргәч, тирә-юнь тагын да нурланыбрак киткәндәй булды. Кешеләр үзара киңәштеләр дә яңа бөркелгән кизләүгә өч баласын калдырып фани дөньядан бакыйлыкка күчкән Гөлмибәян исемен бирергә булдылар.

Суы саф, чиста, эчеп туймаслык. Моңлана-моңлана агымсуларны күзәтеп, табигать белән хозурланып утырышлы ямьле җир барлыкка килде авыл халкы һәм узган-барган өчен. Чүп-чарны җыештырып калдыру өчен махсус савытлар да куелды. Әлегә, шөкер, Гөлмибәян чишмәсе һәммә кешене шатландырып, чистапөхтә килеш тора. Әмма киләчәктә дә ул шулай матурлыгын саклый алырмы, йөзенә тап төшермәсләрме дигән шөбһә күңелгә тынгылык бирми. Ник дигәндә, чишмәләргә карата җаваплсызлык мисаллары муенга җитеп ашкан. Моңа кадәр нефтьчеләр кулы белән савыктырылган күп кенә чишмәләребез бүгенге көнгә беренче матурлыкларын югалтып киләләр. Ә андый изгелекләр Нурлат районында күпләп кылынган иде. "Иске авыл", "Иглай бабай", "Юлдаш", "Изге чишмә" – исемнәре генә дә ни тора! Әмма кайбер кемсәләрнең мәнсезлеге аркасында аларның тирә-юне хәрабәгә әйләнеп килә түгелме? Бала уйнап туйгач өр-яңа уенчыгын атып бәрә, йолкый, ботарлый башлаган кебек, кешеләр дә үзләренә шатлык өләшкән чишмәләргә әкренләп битарафлана башлыйлар. Бәгъзе яшьләр матур чишмә буенда "күңел ачу"ны вату-җимерү белән төгәллиләр.

Хәтерлим әле, Киекле авылының "Изге авыл" чишмәсе янында нинди сихри тынлык, әкияти хозурлык хөкем сөрә иде элегрәк. "Әүлияләр оялаган" шул изге җирнең тынычлыгын бозучы, чишмәнең каралтыкурасын җимерүчеләр дә табылды. Бүгенге "сакаллы сабыйлар", изге суга манчылган кабымлык чәйнәп, акыра-бакыра аракы чөмергәннән соң, үзләренең биниһая кыргыйлык галәмәте белән таң калдыралар. Кулларына шешә тоткан килеш җәелеп утырган эскәмияләрне ватып, учакка ягуны ничек атарга соң? Ә инде чишмә тирәсендә мәктәп укучылары үстергән чәчәк, гөлләргә бөтенләй көн юк. "Культуралы ял итүче"ләрдән соң оламы белән аунап калган нәҗесне кем килеп җыештырыр дип уйлыйлардыр. Хәер, башында уе булганнар андый явызлыкка бармас.

Киекле җирлеге советында юньсез бәндәләр чуарлап, ботарлап калдырган тәртипсезлекләрне игә китерү өчен махсус кеше билгеләргә мәҗбүр булганнар. Әледән-әле санитар көннәр үткәреп торалар икән. Әмма хакимият үзе дә матурлыкны мәсхәрәләүче инсаннарга үтемле йогынты ясый алмаудан гаҗиз.

Кечке якта Яңа Иглай авылы янындагы чишмәгә дә барып чыктык. "Иглай бабай чишмәсе" дип аталган кизләүдә милли нәкыш белән бизәкләп, челтәрләп эшләнгән чатырны, коймаΝы, уңайлы утыргычларны сокланып карарга өлгермәдек, шулар тирәсендә үк "яшел елан" кочагында кәеф-сафа корып мәш килүче берничә егет-җилән һәм кыз-кыркын кәмәшен күреп кәеф кырылды. Изге сулар янәшәсендә, җитмәсә, Рамазан аенда, иман бозып, хәмер чөмерү дә, тирә-якны аракы шешәләре, пакет-кәгазь ише нәҗес ыргытып пычрату да акылга сыймый. Кисәтү ясаган идек яшьләргә, исләре дә китмәде. "Бу безнең өчен ясалган", – дип масаеп, безне мыскыл итеп тик торалар. Кемнән туган мәнсез җаннар дип, кул селтәргә генә калды.

Шушыңа охшаш иләмсез күренешләргә бүтән чишмә буйларында да тап булдык. Җәмгыятебездәге әдәп, тәртип, шәфкать кебек сыйфатларның кимүеннән килә мондый хәлләр. Сәламәтлек чыганагы булган чишмә-коеларны аерым игелекле җаннар гына карап, тазартып бетерә алмый. Җидегән чишмәләр язмышы шул төбәктә торучы һәммә кешенең аңына, әдәп дәрәҗәсенә бәйле. Табигатьне күрәләтә рәнҗетүчеләргә әүлияләр каргышы төшмәс, су иясе тотмас, дип кем әйтә ала. Шушы уйны һәр ата-ана бишектән сабыеның башына сеңдерә килсә генә бүгенге көндәге имансызлыклардан котыла алырбыз.

**Илдус ДИНДАРОВ**

# Төртеп күрсәткәч

**Татарстан Республикасының экологик иминлек буенча ведомствоара комиссия әгъзалары Балтачка республиканың төньяк зонасында бер ел элек үткән утырышның нәтиҗәләре белән танышу өчен бардылар.**

Балтач төньяк зонаның башка районнарыннан эре сәнәгать оешмалары булмау белән аерылып тора. Шулай да район экологиясендә хәл ителмәгән мәсьәләләр байтак икән биредә. Аларны иң борчыганы – суга бәйле мәсьәләләр.

Район халкын эчәр су белән 79 скважина тәэмин итә. Бу якта су каты. Былтыр экологлар андагы тозларның тиешле нормадан берничә тапкыр артыграк булуын билгеләгәннәр. Ул суны йомшарту өчен бер ел эчендә нинди чаралар күрелгәндер, анысын әйтү кыен. Әмма балтачлылар Казан комиссиясен су үзенең катылыгы буенча нормага кереп бара дип ышандырырга тырыштылар. Ә менә пычрак суларны чистарту мәсьәләсе алай тиз генә хәл ителергә охшамаган. Балтач өчен 1974 елда төзелгән чистарту корылмасы бүгенге көнгә бөтенләй эшләми. Чөнки ул шул вакыттан бирле ремонт күрмәгән, диярга була. Былтыр анда 650 мең сумлык төзекләндерү эшләре үткәрелсә дә, корылма эшләп китә алмаган. 2005 елда Балтачта яңа биологик чистарту җайланмасы төзи башлаганнар. Әмма анысы ярты юлда тукталып калган. Төзелешне тәмамлау өчен кирәк 30 миллион сум акчаны район җитәкчеләре берничек юллап ала алмаганнар.

Комиссия әгъзалары Балтачның каты көнкүреш калдыклары полигонында да булдылар. Ул 2001 елдан сафта. 15 елга исәпләнсә дә, балтачлылар аның озаграк хезмәт итүенә өметләнә. Монда чүп аралау линиясе быел гына эшли башлаган. Әмма аңарчы да чүпне күмеп кенә бармаганнар, күрше-тирәдәге эшкәртү оешмалары белән килешүләр төзеп, шунда озата торганнар. Аеруча Чаллы катыргы комбинаты белән элемтәләре тыгыз.

Кунаклар, Балтач гимназиясенә кереп, укучыларга экологик тәрбия бирү торышы белән таныштылар. Менә анысыннан алар бик тә канәгать калды. Укучылар район экологиясенә багышлап ясаган белешмә-сайт Россия бәйгесендә беренче урынны алган. Яшь балтачлылар компьютер экранында гына түгел, тормышта да әйләнә-тирә мохиткә сак караштa. Алар район һәм республикадагы экология бәйгеләрендә катнаша. Өмәләр, чисталык акцияләре үткәрә.

Утырышта Балтачтан тыш, төньяк зонаның башка районнары да җавап тотты. Арча, Әтнә, Кукмара районнарының экология өчен җаваплы вәкилләре ясаган чыгышлар шактый өметле яңгырый. Үткән ел белән чагыштырганда, уңай үзгәрешләр һәр районда күзгә күренеп тора. Әтнә районында, мәсәлән, су чистарту корылмасын ремонтлау эшенә тотынганнар. Ул 2009 ел ахырына тәмамланырга тиеш. Яңа контейнерлар кайтартылып, район үзәгеннән чүп чыгару эше җайга салынган. Хәл ителмәгән төп мәсьәлә булып каты көнкүреш калдыкларын җыю, эшкәртү һәм куркынычсызландыру эшчәнлегенә лицензия алу кала.

Кукмарада су чистарту корылмасын төзекләндерү алгы планда тора. Сөт комбинатының аерым чистарту корылмасы булмаганлыктан, районныкы барлык нәҗес суларны чистартып бетерә алмый. Әмма әлегә аларны төзекләндерү һәм киңәйтү эшенә алынасы оешма да күренеп тормый. Бер ел эчендә иң күп эш башкарылган район дип Арчаны санарга мөмкин. Аларның каты көнкүреш калдыклары полигоны хәзер лицензия белән эшли. Яңа Кенәрдә урнашкан икенче чүп мәйданы да документка ия булу алдында тора. Ә иң мөһиме – арчалылар нәҗес суларны чистарту мәсьәләсен хәл иткән. Ул корылма тулысынча яңартылган: җиһазлар кайтартылып, чистарту технологиясен дә үзгәртүгә ирешкәннәр. Озакламый корылма сафка басачак.

Әлеге күчмә утырышта катнашканнан соң шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: экологик проблемалар, урынга килеп, төртеп күрсәткәннән соң тизрәк хәл ителә икән.

**Ләйсән ФӘҺИМОВА**

Кушымтаның мөхәррире – Илсөяр ХӘЙРУЛЛИНА, биткә салучы һәм бизәүче – Рушан ГЫЙМАЛЕТДИНОВ. Гөлназ САТЕЕВА, Дмитрий БУНТУКОВ фотолары